# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге Караваево авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2024 елның 11 апреленнән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 11 апрелендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлегенең Караваево торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 20.10.2023 ел, № 1 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 111 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 58 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 58 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлегендәге Караваево авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa: «Сез «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлегенең Караваево торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 20.10.2023 ел, № 1 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Ялкын авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Ялкын авыл җирлеге башлыгы ____________ И.В.Гущина
(имза) (имза расшифровкасы)